| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.12.2015 ел Казань ш. № 7-6/т

Яр Чаллы шәһәренең шәһәр элемтә-сендә җәмәгать транспортында пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга максималь дәрәҗәдә чик тарифлар билгеләү турында

«Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 нчы санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 нче санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турында Нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Яр Чаллы шәһәренең шәһәр элемтә-сендә җәмәгать транспортында пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны әлеге карар кушымтасы нигезендә билгеләргә.

2. Үз көчләрен югалткан дип танырга:

«Яр Чаллы шәһәрендә гомуми куллану җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багаж йөрткән өчен максималь тарифлар чикләүләрен билгеләү турында» Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2012 елның 31 маендагы 7-8/т санлы карарының 1нче пункты;

«Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәрендә гомуми куллану шәһәр автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж йөрткән өчен максималь тарифлар чикләүләрен билгеләү турында» Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2014 елның 6 мартындагы 7-2/т санлы карарының 1нче пункты.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча дәүләт комитетының
30.12.2015 № 7-6/т
карарына кушымта

Яр Чаллы шәһәренең шәһәр элемтә-сендә җәмәгать транспортында пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга максималь дәрәҗәдә чик тарифлар

| Транспорт төре | Бер тапкыр йөрү һәм бер багаж йөртү өчен максималь чикләү тарифы (сум) | | |
|---|---|---|---|
| | Транспорт чарасы салонында билет сатып алганда | Йөргән өчен озак вакыт куллану билеты белән түләгәндә | |
| | | Бер тапкыр йөргән өчен[1] | 50 һәм аннан артык йөргән өчен[2] |
| Трамвай | 20 | 18 | 15 |
| Автобус | 20 | 18 | 15 |

<1> шәһәр транспортында йөргәндә теркәлгән сумма чикләрендә йөрү хокукын бирүче өчен озак вакыт куллануда булган билет белән түләгәндә;

<2> шәһәр транспортында йөргәндә билгеләнгән срокта теркәлгән күләмдә йөрү хокукы биргән озак вакыт куллануда булган билет белән түләгәндә.

Искәрмә. Йөк йөртү өчен йөрү өчен түләүдән аерым алып барыла.